**СОВЕТ**
**Кадряковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерже муниципаль районы**
**Кадрәк авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2023 Кадрәк авылы № 21-1

Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының "Кадрәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 49-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. "Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының "Кадрәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 49-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советының карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә. "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.А. Михайлов

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге
Советының 2023 елның 3 февралендәге 21-1
номерлы карары белән расланды

"Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кадрәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 49-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Советы карарына кертелә торган үзгәрешләр

1. 28.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
"5) муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусы алу.".
2. 11.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

"11) аларга чит ил агенты статусы алу.".

3. 20 пунктның 4 пунктчасында "мәҗбүри пенсия иминияте системасында" сүзләрен "мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминләштерү системаларында," сүзләренә алмаштырырга.

4. 11.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11.4 Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.".